СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 353 от 29.04.2020
на № __от _________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында” 2016 елның 5 апрелендәге 45 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яки муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яки муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе хакында” 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында” 2016 елның 5 апрелендәге 45 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яки муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яки муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирүне “Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яки муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яки муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе хакында” 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов